**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

21 июнь 2016 ел Боерган авылы № 6

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2011 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Бирелгән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген кушымта нигезендә расларга.
2. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге турында» Боерган авыл җирлеге башлыгының 2013 елның 16 февралендәге 2 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Боерган авыл җирлеге Башлыгы З.М. Камилҗанов